# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылы торак пунктында
2025елда үзара салым кертү турында

**2024 елның 26 ноябре** **№ 5**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлегенең Каташ-Каран авылында гражданнар җыены

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2025 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Янурыс авыл җирлеге Каташ-Каран авылы торак пунктында I төркем инвалидларыннан, мобилизацияләнгән гражданнардан, шул исәптән катнашучы контрактчылардан (махсус хәрби операция барышында) һәм аларның гаилә әгъзаларенән тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 350 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) Каташ-Каран зиратында куаклар һәм агачлар кисү;

2) Каташ Каран авылындагы юлларны кардан чистарту (спецтехника арендалау, килешү буенча эш өчен түләү).

3) Каташ-Каран торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (светодиодлы лампаларны сатып алу һәм урнаштыру);

4) Каташ-Каран торак пунктында чишмә территориясен төзекләндерү, төзелеш материаллары сатып алу, төзелеш эшләре (килешү буенча эш өчен түләү), куаклар һәм агачлар кисү.

5) Каташ-Каран авылына керү,чыгу юлларына видеокамера җиһазлары алу, урнаштыру.

6) Каташ-Каран урамына юл билгеләре сатып алу, урнаштыру.

7) Каташ-Каран авылында су башнясына баручы юлга таш җәю,тигезләү.

3. Әлеге карарны Янурыс авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Сарман муниципаль районы
Янурыс авыл җирлеге башлыгы,
гражданнар җыенында рәислек итүче А. Ә.Мөхәммәдиева